Республика Татарстан

Исполнительный комитет
Менделеевского
муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль
районы
башкарма комитеты

ПОСТАНОВЛЕНИЕ                                                                     КАРАР

___11.05.2021______      Менделеевск ш.      № ____309______

Торак урыны мәйданының
исәп-хисап нормасы һәм
социаль наем шартнамәсе
буенча торак урыны мәйданын
бирү нормасы турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 50, 58 статьяларын гамәлгә ашыру, дәүләт торак программаларын гамәлгә ашыру максатларында Менделеевск муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районында гражданнарны торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәпкә алу максатларында торак урыны мәйданының гомуми мәйданы белән тәэмин итү дәрәҗәсе гаиләнең бер әгъзасына туры килә торган торак урыны гомуми мәйданының 18 кв. метрдан да күп булмаган күләмендә билгеләнә торган торак урыны мәйданының исәп нормасын билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районында социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннары белән тәэмин ителешнең ирешелгән дәрәҗәсеннән чыгып, социаль наем шартнамәсе буенча торак урыны мәйданын бирү нормасын бер гражданга торак урыны гомуми мәйданының 18 кв. метры күләмендә билгеләргә.

3. Торак урынының гомуми мәйданын бирү нормасын арттыру Россия Федерациясе Торак кодексында каралган очракларда рөхсәт ителә.

4. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының «Исәпкә куелганда торак мәйданы нормалары турында» 2009 елның 30 декабрендәге 1420 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче                                                                     Р.А. Абдуллин

Килештерелде:

Башкарма комитетның
юридик бүлеге начальнигы

Е.С.Царева